Язмача сорап тикшерү төрле мөстәкыйль һәм контроль эшләр уздыру рәвешендә уза. Мөстәкыйль эш-10-20 минут эчендә зур булмаган (әле ахырына кадәр өйрәнелмәгән) тема буенча укучыларның белемнәрен язмача тикшерү. Төп максатларның берсе- укучыларның уку мәсьәләләренең чишелеш алымнарын үзләштерүен, төшенчәләрне аңлавын һәм конкрет кагыйдәләр һәм закончалыклар арасында юнәлеш ала белүен ачыклау. Осталык һәм күнекмәләр формалашуның башлангыч чорында үткәрелгән мөстәкыйль эшләргә билге куелмый. Укытучы укучылар белән бергә башкарган эшкә җентекле анализ ясый. Мөстәкыйль эш барлык укучылар, кечкенә төркемнәр белән индивидуаль рәвештә уздырылырга мөмкин. Аның төрләре индивидуаль үзенчәлекләр, белемнәрне үзләштерүдә укучының алга китеш темпы белән билгеләнә. Тиз арада (5-10 минут) уздырылган мөстәкыйль эшләр фәннең әһәмиятле сораулары буенча укучыларның белем һәм осталыгын тикшерергә һәм белем үзләштерүнең барышына төзәтмәләр кертергә, дөрес эш методикасы сайларга мөмкинлек бирә.

Контроль эш укучыларның белем һәм осталыгын шактый зур, тулысынча өйрәнелгән программа материалы буенча агымдагы һәм йомгаклау фронталь тикшерүдә кулланыла. Язмача тикшерү предметлар буенча ел дәвамында уздырыла ( ана теле, рус теле, математика), язма эш фикерләрне әйтеп бирә белүне, телнең, язма сөйләмнең кагыйдәләрен дөрес куллануны таләп итә.

Өлгерешне тикшерүче стандартлаштырылган методикаларга тестлы биремнәр керә. Тестлар укучының конкрет фәннән ирешкән уңышларын гына түгел, ә бәлки аның гомуми үсеш дәрәҗәсен дә төгәл әйтеп бирә: алган белемне стандарт булмаган ситуациядә куллана белү, дөрес һәм дөрес булмаган җавапларны тикшерү һ.б.

Язмача контрольнең аерым бер төре-график эшләр: рәсемнәр, схемалар, сызымнар, һ.б. Алар теләсә кайсы дәресләрдә кулланылалар. Татар теле дәресендә аваз моделе, җөмлә составы, җөмләне җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерү схемаларын тутыру график контроль эш була.

**Укучыларның ана теленнән белем, осталык, күнекмәләрен тикшерү һәм бәяләү үзенчәлекләре.**

Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары унберьеллык мәктәпнең башлангыч сыйныфлары өчен төзелгән программаларның таләпләренә нигезләнә һәм укучыларның ана телендә язмача башкарган эшләренә бәя бирү критерийларын үз эченә ала.

Укучыларның эшчәнлеген бәяләүгә заман таләпләрен исәпкә алып, башлангыч сыйныфларда “4” баллга нигезләнгән система кертелә. “1”ле, “бик начар” билгесе юкка чыгарыла. Беренчедән, “1”ле башлангыч сыйныфларда гамәлдә кулланылмый, икенчедән аны “2”ле , “начар” билгесенә тиңләштерергә мөмкин.

Беренче сыйныфта ел дәвамында укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә агымдагы тикшерү үткәрелә, ләкин баллар белән билдерелгән билге куелмый, II, III, IV сыйныфларда билге куела.

Ана теле буенча укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләре телдән сорап яки язма рәвештә тикшерелә. Контроль язма эшләр җитәрлек дәрәҗәдә әзерлек булганнан соң гына уздырыла.

**Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләрен язмача бәяләү һәм тикшерү.**

I сыйныфта белем, осталык һәм күнекмәләргә агымдагы тикшерү уздырыла. Грамотага өйрәтү чорында өйрәнелгән баш һәм юл хәрефләрне, иҗекләрне, гади структуралы сүзләрне әйтеп, сүзләрне

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Чт, 15 фев 2024 18:24:38 МСК
Идентификатор документа 44846915-e1f3-4381-899e-f23bc6eab71c

һәм күләме ягыннан кечкенә җөмләләрне язма һәм басма шрифтлы текстган күчереп яздырырга мөмкин.

Уку елы азагында контроль эш итеп басма шрифтлы текстны күчереп, кечкенә күләмле текстны ишетеп язу тәкъдим ителә.

II-IV сыйныфларда контроль эшләр (агымдагы һәм йомгаклау ) гадәттә грамматик биремле диктант (күчереп язу) формасында уздырыла. Грамматик бирем сүз һәм җөмләләрне өлешчә яки тулысынча тикшерүдән тора. Диктант һәм грамматик биремнәр өчен аерым билгеләр куела.

Язма контроль эшләрнең саны һәм төрләре программаның әһәмиятле сораулары яисә укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләрен зур булмаган бер тулы тема буенча тикшерү кирәклеге белән билгеләнә.

Гомуми йомгаклау контроль эшләре программаның аеруча мөһим темаларын үткәч, уку чирегенең, яртыеллыгының, елның азагында уздырылалар һәм укучының барлык темалар буенча әзерлеген тикшерәләр.

Диктант (күчереп язу) өчен бәйләнешле текстлардан файдалану максатка туры килә. Текстлар хәзерге әдәби тел нормаларына туры килергә, тәрбияви һәм белем бирү рәвешендә, эчтәлеге һәм төзелеш ягыннан укучыларга аңлаешлы булырга тиеш.

Диктант өчен уртача авырлыктагы текст алына, аңа элек һәм яңа өйрәнелгән кагыйдәләргә орфограммалар булырга тиеш. Беренче сыйныфка язылышы әйтелешенә туры килгән сүзләрдән торган текст сайлана. Әгәр дә диктант текстында кагыйдәсе өйрәнелмәгән сүзләр яки тыныш билгеләре очраса, алар тактада языла яисә укытучы тарафыннан ачык итеп әйтелә. Сочинениеләр башлангыч сыйныфларда өйрәтү характерында эш итеп уздырыла.

| Сыйныф | Чирек | | | |
|---|---|---|---|---|
| | I чирек | II чирек | III чирек | IV чирек |
| 2<br>3<br>4 | 25 сүз<br>45 сүз<br>65 сүз | 30 сүз<br>50 сүз<br>70 сүз | 35сүз<br>55 сүз<br>75 сүз | 40 сүз<br>60 сүз<br>80 сүз |

I сыйныфта ел дәвамында 2-3 юл һәм баш хәреф, 2-3 иҗек, 2-3 сүз яки 2-3 сүздән торган җөмлә әйтеп яздырыла. Ел азагында 15 сүздән торган текст я диктант итеп, я күчерп язу өчен тәкъдим ителә. Эш телдән әйтеп бәяләнә, нәтиҗәнең программа таләпләренә туры килү-килмәве ачыклана. Ишетеп яки күчереп язган текстта хаталар саны 5тән артмаса, эш канәгатьләнерлек дип табыла.

**II-IVсыйныфларда эш түбәндәгечә бәяләнә:**

**"5"**- хаталар һәм төзәтүләр юк, эш пөхтә, ачык язылган. Язу каллиграфия таләпләренә туры килә (хәрефләрнең формалары дөрес, бертөрле биеклектә, хәрефләр арасында тигез ара, һ.б). каллиграфия нормаларыннан бер генә чигенеш яки бер төзәтү булырга мөмкин (төшеп калган хәрефне өстәү, төгәл язылмаган хәрефне төзәтү, һ.б.)

**"4"** – диктантта 2 орфографик, 1 пунктуацион хата яки 1 орфографик, 2 пунктуацион хата. Эш пөхтә башкарылган, ләкин каллиграфия таләпләре үтәлмәгән. Шуңа өстәп, берәр "5" билгесендә күрсәтелгән төзәтүләр булырга мөмкин.

**"3"**-диктантта 3 тән 5 кә кадәр орфографик хата (3 орфографик, 2 пунктуацион яисә 5 орфографик һәм 1 пунктуацион хата).Эш җиренә җиткереп башкарылмаган, каллиграфия нормаларыннан җитди тайпылышлар. Төрле характердагы төзәтүләр булырга мөмкин.

**"2"**-диктантта 6-7 орфографик хата. Эш тырышып башкарылмаган, каллиграфия нормалары үтәлмәгән.

Диктантта хата итеп исәпләнә: сүзне язганда, орфография кагыйдәсен сакламау, сүздәге хәрефләрне төшереп калдыру, бозып язу, сүзләрне алмаштыру, тыныш билгеләре булмау (программа таләпләренә

бәйле рәвештә), программада язылган сүзләрне хаталы язу.

Диктантта хата итеп исәпләнми: кагыйдәсе өйрәнелмәгән сүзләрдәге хата, алдагы җөмлә азагында нокта булмау, мәгънәгә зыян китермичә, 1 генә сүзне башка сүз белән алмаштыру.

Диктантта 1 хата итеп исәпләнә: 2 хатаны төзәтү, бер типтагы 2 пунктуацион хата, бер үк сүздәге хатаны кабатлау. Тупас хата булып исәпләнми: бер үк сүздәге хәрефләрне 2 тапкыр язу, сүзне юлдан юлга күчергәндә, юл азагында сүзнең башлангыч өлеше язылып, икенче өлешен төшереп калдыру, җөмләдә сүзне 2 тапкыр язу.

Эштә булган һәрбер орфографик һәм пунктуацион хата исәпкә алына. Бер хата итеп, контроль диктантлар өчен күрсәтелгән очраклар исәпкә алына.

Грамматик биремле (2 бирем) диктант (күчереп язу) тексты, өйрәнелгән грамматик материал белән бәйле булырга тиеш, чөнки алар шул материалның үзләштерү дәрәҗәсен һәм укучыларның аны телдән һәм язма сөйләмдә куллана белүен ачыклый.

**Грамматик биремнәрне тикшерү һәм бәяләү:**

**“5”**- хатасыз;

**“4”**-биремнәрнең ¾ өлеше дөрес;

**“3”**-биремнәрнең яртысы дөрес үтәлгән;

**“2”**- биремнәрнең күпчелеге дөрес үтәлмәгән.

Сүзлек диктантлары да контроль эш рәвешендә үткәрелергә мөмкин. Диктант материалы итеп язылышы үзләштерелергә тиешле программада күрсәтелгән сүзләр алына. Күләме-II сыйныф-8-10 сүз, III сыйныф-10-12 сүз, IV сыйныф-12-15 сүз.

**Бәяләү нормалары**

**“5”**- хатасыз эш.

**“4”**- 1 хата, 1 төзәтү.

**“3”**-2 хата, 1 төзәтү.

**“2”**- 3-4 хата.

Укучыларның бәйләнешле язма сөйләм күнекмәләрен өйрәтү рәвешендәге изложениеләр һәм сочинениеләр ярдәмендә тикшереп була. Алар 1 сәгать дәвамында башкарыла. Контроль эш итеп III сыйныфның азагында 1 тапкыр, IV сыйныфта 2 тапкыр уздырыла.

Изложение текстының күләме һәр сыйныф өчен күрсәтелгән диктант текстыннан 15-20 сүзгә артык булырга тиеш.

Изложение өчен хикәяләү рәвешендәге текстлар алына, III сыйныфта тасвирлау һәм фикер йөртү элементлары кертергә мөмкин. Текстларның эчтәлеге тәрбияви юнәлешле һәм балаларга аңлаешлы булырга тиеш.

Сочинениеләрнең күләме III-IV сыйныфларда 0,5 биттән 1 биткә кадәр; бу якынча III сыйныфта 9-10 җөмлә (50-60сүз), IV сыйныфта 11-12 җөмлә (70-80 сүз).

Сочинениеләрнең темасы балаларның тормыш тәҗрибәсенә, мәнфәгатенә якын, сүзлек составы һәм төзелеше ягыннан укучылар башкара алырлык булырга тиеш.

Изложение һәм сочинениеләрне бәяләү критерийлары: текст эчтәлегенең тулы һәм эзлекле язып бирелүе (изложениедә), текст төзү (сочинениедә), сөйләм ягыннан оештыру, грамоталылык.

II-IV сыйныфларда изложение һәм сочинениеләр өчен 1 билге куела. Хаталар исәбе диктанттагы

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Чт, 15 фев 2024 18:24:38 МСК
Идентификатор документа 44846915-e1f3-4381-899e-f23bc6eab71c 

кебек алып барыла. Аларның эчтәлек һәм сөйләм ягыннан оештырылуы түбәндәгечә тикшерелә:

кирәге булмаган фактлар кертү, текстның өлешләре арасында бәйләнеш булмау, җөмләләрнең бер-бер артлы уңышсыз тезелүе, бер үк сүзне кирәксезгә кабатлау, сүзне тиеш булмаган мәгънәдә куллану.

**Иҗади эшләр түбәндәгечә бәяләнә:**

**“5”**- автор текстын дөрес һәм эзлекле итеп чагылдыру (изложениедә), теманы логик эзлеклелектә ачып бирү, фактик хаталарның булмавы, сүзлекнең бай булуы һәм эшнең сөйләм ягыннан дөрес оештырылуы. 1 сөйләм төгәлсезлеге булырга мөмкин. Өйрәнелгән кагыйдәләргә орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, 1-2 төзәтү бар.

**“4”**-автор тексты җитәрлек дәрәҗәдә тулы бирелгән (изложениедә), тема ачылган, ләкин эчтәлекне биргәндә, сизелмәслек кенә булса да, эзлеклелек бозылган, аерым фактик һәм сөйләм төгәлсезлекләре бар. Тулаем алганда, сөйләм, шулай ук текстның эчтәлегендә, төзелешендә 3 төгәлсезлек булырга мөмкин. 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хата, 1-2 төзәтү бар.

**“3”**- автор текстыннан бераз читкә китү күзәтелә (изложениедә), темадан читкә тайпылыш, нигездә дөрес, тик эчтәлекне язганда эзлеклелек юк, 2-3 җөмлә дөрес төзелмәгән, сүзлек ярлы, сөйләм төгәлсезлекләре бар. Текстның эчтәлегендә һәм төзелешендәге җитешсезлекләр саны 5 тән артмаска тиеш. 3-5 орфографик, 1-2 пунктуацион хата, 1-2 төзәтү бар.

**“2”**-темага туры килсә дә, автор текстыннан сизелерлек тайпылыш бар (изложениедә), күпсанлы фактик хаталар җибәрелгән,эчтәлекне язып бирүдә эзлеклелек югалган. Эшнең аерым кисәкләре арасында бәйләнеш юк, сүзлек ярлы. Сөйләм төгәлсезлекләре һәм эчтәлекне язып бирүдә һәм эшнең төзелешендә 6 дан артык хата. Орфографик хаталар саны-6 һәм аннан да артык, 3-4 пунктуацион хата, 3-5 төзәтү бар. Иҗади эшләргә билге куйганда, шулай ук аның пөхтә, ачык башкарылганлыгы да исәпкә алына. Таләпләр диктанттагы кебек.

**Белем,осталык һәм күнекмәләргә йомгаклау билгеләре.**

Йомгаклау билгесе һәр чирек һәм уку елы азагында куела. Ул грамоталылыкны, грамматика элементларының үзләштерелү дәрәҗәсен, материалны бәйләнешле итеп сөйли алу осталыгын телдән җавап сорап һәм язмача тикшерү нәтиҗәләрен исәпкә алып куела. Язма эшләрнең нәтиҗәсенә өстенлек бирелә. Әгәр дә укучының чирек дәвамында язма эшләр өчен уңай билгеләре булмаса, аңа татар теленнән уңай билге чыгарылмый. Йомгаклау билгесе укучының барлык күрсәткечләр буенча фактик әзерлеген бәяли, ул барлык билгеләрнең уртача саны була алмый.

**Конроль күчереп язуны бәяләү**

| Билге | Хаталар саны | | |
|---|---|---|---|
| | II сыйныфта | III сыйныфта | IV сыйныфта |
| “5” | Хатасы юк. Язуга караган бер төгәлсезлек булуы мөмкин. | Хатасы юк. | Хатасы юк. |
| “4” | 1-2 хата, төзәтү | 1 хата, 1 төзәтү | 1 хата, 1 төзәтү |
| “3” | 3 хата, 1 төзәтү | 2 хата 1төзәтү | 2 хата, 1 төзәтү |
| “2” | 4 хата, 1-2 төзәтү | 3 хата, 1-2 төзәтү | 3 хата, 1-2 төзәтү |

**Нормы оценки знаний, умений и навыков учащихся по предмету «Литературное чтение на родном (тат.)языке».**

Белемнәрне тикшерү һәм аның сыйфатын бәяләү укучылар ирешкән белем дәрәҗәсенең башлангыч мәктәпне тәмамлаучылардан таләп ителгән белем һәм күнекмәләргә туры килү-килмәвен чагылдыра. Белемнәрне тикшерү һәм бәяләү җәмәгатьчелеккә (сыйныф укучыларына, укытучыларга, ата-

аналарга) һәм хөкүмәткә бер конкрет мәктәптә генә түгел, ә бәлки бөтен җәмгыятьтәге белемлелек дәрәҗәсен күрсәтә. Бу белем бирүнең ерак һәм якын перспективасын билгеләргә, белем бирү системасына вакытында төзәтмәләр кертеп, укучыларга һәм укытучыга кирәкле ярдәм күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Укучыларның белемен вакытында һәм объектив бәяләү укытучыга педагогик процессны оештырудагы кимчелекләрне, үз эшендәге хаталарны күрергә ярдәм итә.

Объектив бәяләү системасы белемнәрнең сыйфатын гына ачыклап калмый, ә бәлки балаларның үз эшләрен тикшерә белү сәләтен ачыклый һәм тикшерүдән котелгән куркулы һәм борчулы хәлне булдырмый кала. Укытучы балаларны уңыш казануга дәртләндерергә һәм нәтиҗәләрнең уңай якка үзгәрәчәгенә ышаныч тудырырга тиеш. Уңыш казануга юнәлтелгән ситуация һәм эмоциональ иминлек баланың укытучы куйган билгене тыныч кабул итүенә китерә, укучы укытучы белән бергә үз хаталарын тикшерә һәм аларны булдырмау юлларын билгели.

**Уку нәтиҗәләрен тикшерү төрләре.**

*Агымдагы контроль* – укытуның башлангыч этапларында, белем һәм күнекмәләрнең формалашып җитмәгән чорында уздырыла. Аның төп максаты- белем һәм күнекмәләр формалашуның барышын тикшерү. Бу укучыларга һәм укытучыга вакытында үз җитешсезлекләрен күрергә, сәбәпләрен ачыкларга һәм аларны булдырмау өчен чаралар эзләргә, үзләштерелмәгән кагыйдәләргә, эш алымнарына әйләнеп кайтырга мөмкинлек бирә. Бу вакытта укучының ялгышырга, укытучы белән берлектә уку эше алымнарына җентекле анализ ясарга хокукы булырга тиеш. Һәр хата өчен җәза бирүче цифр белән белдерелгән билге куярга ашыгырга ярамый, фикер йөртү тәртибендәге анализ, хаталарны төзәтү юлларын аңлатуның әһәмияте арта.

*Тематик контроль* программадагы һәр зур теманың үзләштерелүен тикшерә, ә билге ирешкән нәтиҗәне күрсәтә. Бу төр тикшерүнең үзенчәлекләре:

1)укучыга материалны яңадан,өстәп тапшыру, элек алган билгене төзәтү мөмкинлеге бирелә;

2)укытучы йомгаклау билгесен куйганда, уртача баллга карамый, тикшерелә торган теманың соңгы билгеләрен исәпкә ала, бу билгеләр элеккеге түбәнрәк билгеләрне “юкка чыгара”;

3)белемнәреңә югарырак бәя алу мөмкинлеге туа.Белемнәрне тирәнәйтү һәм төгәлрәк итү укуның мотивациясенә әверелә, укучының укуга теләген һәм кызыксыну дәрәҗәсен арттыра.

*Йомгаклау контроле* чирек, яртыеллык, ел эчендә укыту нәтиҗәләрен тикшерү формасында була. Күчерелеш билгеләрен куйганда, югарырак билгеләргә өстенлек бирелә.

**Контроль уздыруның методлары һәм формалары.**

*Телдән сорап тикшерү* укучыдан материалны сөйләп бирүне, әйләнә- тирәдәге нинди дә булса объект турында бәйләнешле хикәяләүне таләп итә. Мондый сорап тикшерү әңгәмә, укучының сөйләве, аңлатма, текстны уку, күзәтүләр һәм тәҗрибә турында хәбәр итү формасында оештырылырга мөмкин.

Телдән сорап тикшерү укуның беренче этапларында укучының белемнәренә системалылык һәм төгәллек кертү өчен, укытучының бер укучы белән кара-каршы сөйләшүе рәвешендә үтә. Уку диалогы өчен нык уйланылган сораулар системасы булуы кирәк. Чөнки укучының информацияне хәтерендә калдыруы һәм яңадан әйтеп бирә белүе генә түгел, ә бәлки аңлы үзләштерүе, фикер йөртүе, үз фикерен әйтү сәләте, җавабын дәлилли белүе, гомуми әңгәмәдә катнашуы, гомуми төшенчәләрне конкретлаштыра алуы тикшерелә.

Башлангыч сыйныфларда телдән җавап бирүнең монологик формасы еш очрамый. Бу балаларга телдән җавап бирү өчен бирелгән материалның кечкенә күләмле булуы белән бәйле, шуңа күрә монологик җавап таләп итә торган проблемалы сораулар укучыдан иҗади якын килүне, мөстәкыйльлелек, зирәклек таләп итә. Алар өйдә өйрәнелгән дәреслек текстынкабатлап сөйләүгә генә кайтып кала алмый.

*Язмача сорап тикшерү* төрле мөстәкыйль һәм контроль эшләр уздыру рәвешендә уза.

*Мөстәкыйль эш-* 15-20 минут вакыт эчендә зур булмаган ( әле ахырына кадәр өйрәнелмәгән) тема

буенча укучыларның белемнәрен язмача тикшерү. Төп максатларның берсе- укучыларның уку мәсьәләләренең чишелеш алымнарын үзләштерүен, төшенчәләрне аңлавын һәм конкрет кагыйдәләр һәм закончалыклар арасында юнәлеш ала белүен ачыклау. Осталык һәм күнекмәләр формалашуның башлангыч чорында үткәрелгән мөстәкыйль эшләргә билге куелмый. Укытучы укучылар белән бергә башкарылган эшкә җентекле анализ ясый.

Мөстәкыйль эш барлык укучылар, кечкенә төркемнәр белән индивидуаль рәвештә уздырылырга мөмкин. Аның төрләре индивидуаль үзенчәлекләр, белемнәрне үзләштерүдә укучының алга китеш темпы белән билгеләнә.

Тиз арада (5-10 минут) уздырылган мөстәкыйль эшләр фәннең әһәмиятле сораулары буенча укучыларның белем һәм осталыгын тикшерергә һәм белем үзләштерүнең барышына төзәтмәләр кертергә, дөрес эш методикасы сайларга мөмкинлек бирә.

*Контроль эш* укучыларның белем һәм осталыгын шактый зур, тулысынча өйрәнелгән программа материалы буенча агымдагы һәм йомгаклау фронталь тикшерүдә кулланыла. Язмача тикшерү предметлар буенча ел дәвамында уздырыла (ана теле, рус теле, математика), язма эш фикерләрне әйтеп бирә белүне, телнең, язма сөйләмнең кагыйдәләрен дөрес куллануны таләп итә.

Өлгерешне тикшерүче стандартлаштырылган методикаларга тестлы биремнәр керә. Тестлар укучының конкрет фәннән ирешкән уңышларын гына түгел, ә бәлки аның гомуми үсеш дәрәҗәсен дә төгәл әйтеп бирә: алган белемне стандарт булмаган ситуациядә куллана белү, дөрес һәм дөрес булмаган җавапларны чагыштыру һ.б.

Язмача контрольнең аерым бер төре- график эшләр: рәсемнәр, схемалар, сызымнар һ.б. Алар теләсә кайсы дәресләрдә файдаланылалар.

**Укучыларның әдәби укудан белем, осталык, күнекмәләрен тикшерү һәм бәяләү үзенчәлекләре.**

Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары унберьеллык мәктәпнең башлангыч сыйныфлары өчен төзелгән программаларның таләпләренә нигезләнә һәм укучыларның ана телендә телдән һәм язмача башкарган эшләренә бәя бирү критерийларын үз эченә ала.

Беренче сыйныфта ел дәвамында укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә агымдагы тикшерү үткәрелә, ләкин баллар белән белдерелгән билге куелмый. II,III, IV сыйныфларда билге куела.

**Уку күнекмәсен тикшерү.**

Уку күнекмәсе һәр сыйныф өчен программада билгеләнгән таләпләр нигезендә бәяләнә.

**I сыйныф**

Беренче уку елы дәвамында элементар уку күнекмәсе билге куймыйча гына тикшерелә. Тикшерүнең төп объекты – укучыларның сүзгә иҗек-аваз анализы ясый белүе, өйрәнелгән кергән сүзләрне, җөмләләрне, кыска текстларны салмак, иҗекләп укый алуы. Уку елы азагында программа таләп иткән башлангыч уку күнекмәсе тикшерелә. Укучылар текстларны дөрес, салмак, иҗекләп, минутына 30 сүз укырга тиеш. Нәтиҗәгә телдән бәя бирелә.

**II сыйныф**

**“5”(“бик яхшы”)**- дөрес уку, укыганның эчтәлеген аңлау.

- I яртыеллыкта иҗекләп, кыска сүзләрне бөтен килеш уку, тизлеге минутына 40 сүз;
- II яртыеллыкта салмак, сүзләп уку (читен сүзләрне генә иҗекләп уку), уку тизлеге –минутына 50 сүз, авазларны, сүзләрне ачык әйтү, сүздәге авазларны, иҗекләрне бозмый, урыннарын алмаштырмыйча уку;
- сүз басымын дөрес кую, җөмлә азагындагы тыныш билгесенә карата пауза һәм интонацияне саклау;
- укытучының соравына тексттан җавап таба белү, укылган текстның һәм аның иллюстрацияләренең эчтәлеген эзлекле рәвештә сөйләп бирү;

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Чт, 15 фев 2024 18:24:38 МСК
Идентификатор документа 44846915-e1f3-4381-899e-f23bc6eab71c 

- яттан өйрәнелгән шигырьне  яхшы белү һәм сәнгатьле сөйләү.

**“4”( “яхшы”)**- әсәрнең төп эчтәлеген аңлау:

- I яртыеллыкта салмак,тулы сүзәп (читен сүзләрне иҗекләп) уку, тизлек- минутына 40 сүз;
- II яртыеллыкта салмак, тулы сүзләп  (читен сүзләрне иҗекләп), минутына 50 сүз уку; басым куюда, җөмлә ахырында пауза ясаганда һәм интонация сайлаганда, 1-2 хата булырга мөмкин;
- укылган текстның эчтәлеген дөрес сөйләү, укытучы сорауларына  дөрес  җавап бирү, сөйләмдә үзе яки укытучы ярдәме белән генә төзәтерлек  төгәлсезлекләр булырга мөмкин;
- шигырьне яттан белү, ләкин сөйләгәндә сүзләрнең урыннарын алмаштыру, хаталарны җиңел һәм мөстәкыйль төзәтү.

**“3” (“канәгатьләнерлек”)**- укылган текстның эчтәлеген укытучы ярдәмендә генә аңлау:

- I яртыеллыкта өзек-өзек, иҗекләп ( аерым сүзләрне бөтен килеш) уку,  уку тизлеге минутына 30 сүздән ким түгел;
- II яртыеллыкта салмак, иҗекләп  ( аерым сүзләрне бөтен килеш) уку,  тизлек- минутына 40 сүз, иҗекләрне, сүзләрне алмаштыру, төшереп калдыру, урыннарын алмаштыруга 3-5 хата булу, сүзләр, җөмләләр арасында пауза сакламау;
- эчтәлекне сөйләгәндә, тексттагы эзлеклелекне югалту, сөйләм хаталары һәм аларны укытучы ярдәме белән генә төзәтү;
- шигырьне яттан белү,  сөйләгәндә  текстның ныклы өйрәнелмәгәнлеге ачыклану.

**“2”(“начар”)**- укылган текстның эчтәлеген укытучы ярдәме белән дә аңлый алмау:

- I яртыеллыкта хәрефләп уку, ,  уку тизлеге- минутына 25 сүз;
- II яртыеллыкта  өзек-өзек, иҗекләп, хәрефләп уку элементларын кертеп уку, уку тизлеге- минутына 35 сүз,  укыганда иҗекләрне алмаштыруга, төшереп калдыруга 6 дан артык хата булу, сүзләр һәм җөмләләр арасында паузаны сакламау;
- укытучы сораулары ярдәме  белән дә эчтәлекне сөйли алмау;
- яттан сөйләгәндә эзлеклелекне бозу, текстны тулысынча әйтә алмау.

### III сыйныф

**“5”**- укыганның мәгънәсен дөрес аңлау.

- I яртыеллыкта  сүзләп (таныш булмаган, иҗек  структурасы катлаулы сүзләрне иҗекләп), хатасыз уку,  уку тизлеге – минутына 60 сүз;
- II яртыеллыкта  сүзләп уку, тизлеге- минутына 75 сүз;
- текстны сәнгатьле уку, мәгънә ягыннан кирәкле сүзләрне  аерып күрсәтә белү һәм паузаларны саклау;
- укыганның эчтәлеген җентекле һәм сайлап сөйләү;
- зур булмаган текстны  мөстәкыйль рәвештә кисәкләргә бүлә һәм аларга исем куя белү, эчтәлекне гади планга таянып сөйләү, бирелгән сорауга җавапны тексттан өзекләр китереп ныгытып кую;
- ятлаган шигырьне ныклы белү һәм аны сәнгатьле сөйләү.

**“4”**- укыганның төп эчтәлеген дөрес аңлау:

- I яртыеллыкта  сүзләп сәнгатьле уку (аерым сүзләрне иҗекләп), уку тизлеге-55 сүз;
- II яртыеллыкта  уку тизлеге- минутына 70 сүз, укыганда 1-3 хата булырга мөмкин;
- текстны    мөстәкыйль рәвештә кисәкләргә бүлгәндә, кирәкле эпизодларны тапканда, 1-2 төгәлсезлек булу һәм аларны укытучы ярдәменнән башка төзәтү;
- шигырьне яттан белү, сәнгатьле сөйләү, кирәксез кабатлау, сүзләрнең урыннарын алмаштыру кебек төгәлсезлекләр җибәрү;

**“3”**- укыган текстның төп эчтәлеген укытучы ярдәмендә билгеләү:

- I яртыеллыкта текстны сүзләп уку белән бергә иҗекләп уку элементларының булуы, үзгәрешсез тавышлы уку, тизлеге 50 сүздән дә ким булмаска тиеш;
- II яртыеллыкта уку тизлеге- минутына 65 сүз, укыганда хәрефләрне, иҗекләрне, сүзләрне алмаштыру, төшереп калдыру, бозып әйтүгә 4-6 хата булуы, сүз басымын ялгыш кую;
- мөстәкыйль рәвештә, укытучының юнәлтүче сорауларыннан башка укыганның эчтәлеген эзлекле итеп сөйләмәү, текстны кисәкләргә бүлә һәм исем куя алмау, сөйләм хаталарын укытучы ярдәме белән генә төзәтү;
- яттан шигырьне ныклы белмәү.

**“2”**- I яртыеллыкта бертөрле тавыш белән иҗекләп уку, уку тизлеге минутына 45 сүздән ким булмаска тиеш:

- II яртыеллыкта күп сүзләрне иҗекләп, аерым сүзләрне бөтен килеш уку, уку тизлеге- минутына 50 сүзгә якын;
- укыганда 6 дан артык хата җибәрү;
- укыганның эчтәлеген үзгәртеп сөйләү, өстәмә сораулар булса да , текстны кисәкләргә бүлә алмау;
- ятлаган шигырьне тулысынча сөйли алмау.

**IV сыйныф**

**“5”** – укыганның эчтәлеген тулы һәм дөрес аңлау:

- сүзләп йөгерек уку, әдәби телнең әйтелеш нормаларын үтәү;
- I яртыеллыкта уку тизлеге минутына 85 сүздән;
- II яртыеллыкта - минутына 95 сүздән дә ким түгел;
- сәнгатьле укуга мөстәкыйль рәвештә әзерләнү һәм интонация ярдәмендә әсәрнең мәгънәсен, аңа үз мөнәсәбәтен белдерә алу;
- текстның тулы, кыскача һәм сайлап эчтәлеген сөйләп бирү, укыганның төп фикерен үз сүзләрең белән әйтеп бирү;
- әсәрнең геройларын, вакыйгаларын, табигатьне сурәтләүче сүзләрне һәм җөмләләрне мөстәкыйль рәвештә табу;
- шигырь текстын ялгышмыйча, сәнгатьле итеп сөйләү;

**“4”** –укыганның төп эчтәлеген дөрес аңлау:

- сүзләп, сәнгатьлелекнең төп чараларын файдаланып уку;
- I яртыеллыкта уку тизлеге- минутына 80 сүз;
- II яртыеллыкта уку тизлеге- минутына 90 сүз, укыганда 1-3 хата булырга мөмкин;
- укыганның төп фикерен мөстәкыйль рәвештә билгели алу, сөйләм хаталары булу, аларны укытучы ярдәменнән башка да төзәтә алу;
- эчтәлекне тулы, кыска, сайлап сөйләгәндә, исәпкә алынмаслык төгәлсезлекләр булу;
- ятлаган шигырьне сөйләгәндә, вакытында төзәтелгән 1-2 хата җибәрү.

**“3”**- укыганның эчтәлеген укытучы ярдәме белән генә аңлау:

- I яртыеллыкта үзгәрешсез тавыш белән сүзләп уку (сирәк сүзләрне-иҗекләп уку элементлары катнаштырып), уку тизлеге-75 сүз;
- II яртыеллыкта сүзләп укыганда, сәнгатьлелек булмау, уку тизлеге – минутына 85 сүз, укыганда 4 тән алып 6 га кадәр хата булырга мөмкин;

- укыганның  кыскача эчтәлеген , төп фикерен укытучы сораулары ярдәмендә генә аңлау һәм билгели алу;
- шигырьне яттан сөйләгәндә, ясаган хаталарны укытучы ярдәмендә генә төзәтү.

**“2”** – укыганның эчтәлеген начар аңлау:
- I яртыеллыкта иҗекләп, кайбер сүзләрне генә бөтен килеш уку, иҗекләрне, сүзләрне алмаштыру, төшереп калдыру, бозып әйтүгә күпсанлы хаталар, уку тизлеге –минутына 60 сүз;
- II яртыеллыкта сүзләп укый алмау, 6 дан артык хата, уку тизлеге – минутына 70 сүз;
- эчтәлекне эзлекле сөйли алмау,укыганның эчтәлеген нык үзгәртеп күрсәтү, күпсанлы сөйләм хаталары җибәрү;
- текстның  кыскача,  сайлап эчтәлеген сөйли алмау, план төзи белмәү, укыганның эчтәлеген укытучы ярдәме белән дә билгели алмау;
- ятлаган шигырьнең тулы текстын сөйли  алмау.

Дәрестә уку буенча билге укучының телдән җавап биргәне, мөстәкыйль укыганы өчен куела. Билгегә укылган текстның күләме түбәндәгечә булырга тиеш:
II сыйныф- уку китабының 1/4 бите;  III сыйныф- 1/3 бите, IV сыйныф- ½ бите.
Билгене  аңлатып куярга  һәм укучыларны дөрес уку күнекмәсе булдыруга һәм китап белән эшләргә өйрәнүгә дәртләндерергә кирәк.
Уку күнекмәсен тикшерү елына ике тапкыр: I һәм II яртыеллык азагында уздырыла.

### Телдән җавап бирүне  тикшерү

Укучыларның  телдән җавап бирүен тикшерү программаның нинди дә булса бүлегеннән бирелгән сораулар формасында уза. Билге куйганда, түбәндәгеләр исәпкә алына:
1) җавапның дөреслеге һәм тулылыгы;
2) белемнәрнең аңлы үзләштерелү дәрәҗәсе;
3) сөйләм эзлеклелеге һәм культурасы.

Укучыларның җавабы, бигрәк тә III-IV сыйныфларда, укытучы әйткән тема буенча бәйләнешле сөйләм булып, өйрәнелгән материалның аңлы үзләштерелгәнен күрсәтеп торырга тиеш. Җавапны кагыйдә, билгеләмә, мисал китереп дәлилләү, укытучы кушуы буенча тексттан грамматик категорияләрне таба белү (җөмлә кисәкләре, сүз төркемнәре, килеш, сан һ.б.), тиешле кагыйдәгә караган сүзләр табу, сүзләрнең язылышын аңлату, алган белемнәрне мөстәкыйль рәвештә күнегүләр эшләгәндә һәм, барыннан да элек, сүзләр һәм җөмләләр тикшергәндә (аваз-хәреф анализы, сүзнең составын, аны сүз төркеме буларак тикшерү) куллана белү.

Сөйләм үстерүнең башлангыч чорында ук укучыларның җаваплары дәлилле, тиешле дәрәҗәдә мөстәкыйль һәм дөрес оештырылган булырга тиеш ( фикер йөртүнең эзлекле булуы, сүзләрне, сүзтезмәләрне кулланганда, җөмләләр төзегәндә, әдәби тел нормаларын үтәү).

**“5”**- укучының  җавабы дөрес һәм  тулы, программа материалын  аңлы үзләштерелгәне күренә, җавабын үз мисаллары белән  раслый, сүзләрне, җөмләләрне тикшергәндә, өйрәнелгән грамматик категорияләрне тексттан тапканда, алган белемнәрен  мөстәкыйль рәвештә һәм  дөрес куллана, сүзләрнең язылышын, тыныш билгеләренең куелышын аңлата, бәйләнешле, эзлекле һәм хатасыз җавап бирә, бер төгәлсезлек булырга мөмкин.

**“4”**- укучының җавабы, нигездә “5” билгесенә куелган таләпләргә җавап бирә, ләкин сөйләмдә, кагыйдәгә мисал китергәндә, текст өстендә эшләгәндә, сүзләрне, җөмләләрне  тикшергәндә, 1-2 хата

ясый. Аларны мөстәкыйль рәвештә яки укытучының сизелмәслек кечкенә ярдәме белән төзәтә.

**“3”-** укучы, нигездә, сөйләгән материалны аңлый, ләкин җавабы тулы түгел, укытучының өстәмә сораулары таләп итеlә. Кагыйдәгә мисал китергәндә, кыенлык кичерә, текст белән эшләгәндә, сүзләр һәм җөмләләрне тикшергәндә, хаталар ясый һәм аларны укытучы ярдәменнән башка төзәтә алмый. Сөйләмендә бәйлелек, эзлеклелек җитми, сүз кулланууда, сүзтезмәләр һәм җөмлә төзегәндә, төгәлсезлекләр була.

**“2”-** укучы өйрәнелгән материалның мөһим фикерләрен, зур өлешен белми, кагыйдәләрне, билгеләмәләрне әйткәндә, сүз һәм җөмләләргә анализ ясаганда, хата җибәрә, аларны укытучының өстәмә сораулары ярдәмендә дә төзәтә алмый, сөйләме өзек-өзек, бәйләнешсез, хаталы.

Программада таныштыру максаты белән генә бирелгән материал буенча контроль эшләр уздырылмый.

**Нормы оценки знаний, умений и навыков учащихся по предмету «Технология»**

***Устный опрос***

**«5»** – учащийся полностью освоил учебный материал;
умеет изложить его своими словами; самостоятельно подтверждает ответ
конкретными примерами;
правильно и обстоятельно отвечает на дополнительные вопросы учителя. **«4»** – учащийся в основном усвоил учебный материал, допускает незначительные
ошибки при его изложении своими словами; подтверждает ответ
конкретными примерами;
правильно отвечает на дополнительные вопросы учителя.
**«3»** – учащийся не усвоил существенную часть учебного материала;
допускает значительные ошибки при его изложении своими словами; затрудняется подтвердить ответ конкретными примерами; слабо отвечает на дополнительные вопросы.
**«2»** – учащийся почти не усвоил учебный материал;
не может изложить его своими словами; не может подтвердить ответ конкретными примерами;
не отвечает на большую часть дополнительных вопросов учителя.

***Выполнение графических заданий и лабораторно-практических работ***

**«5»** – учащийся творчески планирует выполнение работы;
самостоятельно и полностью использует знания программного материала; правильно и аккуратно выполняет задание; умеет пользоваться справочной литературой, наглядными пособиями, приборами и другими средствами.
**«4»** – учащийся правильно планирует выполнение работы;
самостоятельно использует знания программного материала; в основном правильно
и аккуратно выполняет задание;
умеет пользоваться справочной литературой, наглядными пособиями, приборами и другими средствами.
**«3»** – учащийся допускает ошибки при планировании выполнения работы; не может самостоятельно использовать значительную часть знаний программного материала;
допускает ошибки и неаккуратно выполняет задание; затрудняется самостоятельно использовать справочную литературу, наглядные пособия, приборы и другие средства.
**«2»** – учащийся не может правильно спланировать выполнение работы;
не может использовать знания программного материала; допускает грубые ошибки и неаккуратно выполняет задание;

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Чт, 15 фев 2024 18:24:38 МСК
Идентификатор документа 44846915-e1f3-4381-899e-f23bc6eab71c

не может самостоятельно использовать справочную литературу, наглядные пособия, приборы и другие средства.

***Практическая работа***

**«5»** – работа выполнена в заданное время, самостоятельно, с соблюдением технологической последовательности, качественно и творчески;

**«4»** – работа выполнена в заданное время, самостоятельно, с соблюдением технологической последовательности, при выполнении отдельных операций допущены небольшие отклонения; общий вид изделия аккуратный;

**«3»** – работа выполнена в заданное время, самостоятельно, с нарушением технологической последовательности, отдельные операции выполнены с отклонением от образца (если не было на то установки); изделие оформлено небрежно или не закончено в срок;

**«2»** – ученик самостоятельно не справился с работой, технологическая последовательность нарушена, при выполнении операций допущены большие отклонения, изделие оформлено небрежно и имеет незавершенный вид.

***Тест***

**«5»** – получают учащиеся, справившиеся с работой на 100–90 %.

**«4»** – верные ответы составляют 80 % от общего количества.

**«3»** – 50–70 % правильных ответов.

***Критерии оценки проекта:***

- Оригинальность темы и идеи проекта.
  - Конструктивные параметры (соответствие конструкции изделия; прочность, надежность; удобство использования).
  - Технологические критерии (соответствие документации; оригинальность применения и сочетание материалов; соблюдение правил техники безопасности).
  - Эстетические критерии (композиционная завершенность; дизайн изделия; использование традиций народной культуры).
  - Экономические критерии (потребность в изделии; экономическое обоснование; рекомендации к использованию; возможность массового производства).
  - Экологические критерии (наличие ущерба окружающей среде при производстве изделия; возможность использования вторичного сырья, отходов производства; экологическая безопасность).
  - Информационные критерии (стандартность проектной документации; использование дополнительной информации).

**Нормы оценки знаний, умений и навыков учащихся по предмету «<u>ОРКСЭ (защита проекта)</u>**

**<u>Проект</u>**

Проектная деятельность предлагается ученикам в конкретных темах. Цель: 1.повысить интерес учащихся к исследовательской деятельности в рамках предмета, 2. повысить уровень самостоятельной работы с различными источниками информации, 3. развитие познавательной активности учеников

Оценивание проекта осуществляется набором баллов, которые ученик получает на протяжении выполнении всей проектной деятельности. Куда входят:

1.целеполагание

2.формулирование задач

3. выдвижение гипотез

4.работа с информацией

5.практическая деятельность

6.анализ и рефлексия.

50 % выполнения работы – оценка удовлетворительная, 70 % - хорошо, 90 % – отлично.

**Русский язык 1 класс (контрольное списывание)**

| Уровни | Допустимое количество ошибок |
|---|---|
| «высокий » | Вся работа выполнена безошибочно и нет исправлений |
| «выше среднего» | Нет ошибок, 1 исправление<br>. |
| «средний» | 1-2 ошибки и 1 исправление. |
| «ниже среднего» | 3 ошибки и 1 исправление. |
| «недостаточный» | Больше, чем принято для выставления оценки «ниже среднего». |

За ошибку в работах считается любая практически допущенная ошибка орфографического и пунктуационного характера.

**Математика(контрольная работа)**

**«высокий уровень»** ставится, если вся работа выполнена безошибочно и нет исправлений цифр.

**«выше среднего»** ставится, если в работе допущены 1-2 вычислительные ошибки, есть исправления, связанные с цифрами.

**«средний»** ставится, если в работе допущена ошибка в ходе решения задачи при правильном выполнении всех остальных заданий или допущены 3-4 вычислительные ошибки при отсутствии ошибок в ходе решения задачи.

**«низкий»** ставится, если допущена ошибка в ходе решения задачи и хотя бы 1 вычислительная ошибка или при решении задачи и примеров допущено более 5 вычислительных ошибок.

**Родной язык (контрольное списывание)**

| Бәяләү | Хаталар саны |
|---|---|
| « югары » | Хаталарсыз, эш пөхтә башкарылган. |
| «уртачадан югары » | Хаталарсыз, 1 төзәтү.<br>. |
| «уртача» | 1-2 хата һәм 1 төзәтү. |
| “уртачадан түбән» | 3хата һәм 1 төзәтү. |
| «түбән» | 4 һәм аннан да күбрәк хата. |

**Литературное чтение (диагностическая работа)**

96% - 100% - уровень « высокий »
91% - 95 % - уровень «выше среднего».
66% - 90% - уровень «средний»,
50% - 65% - уровень «ниже среднего»,
Менее 50% - уровень «недостаточный»,

**Литературное чтение на родном языке**

96% - 100% -“югары” дәрәҗә
91% - 95 % -“уртачадан югары”дәрәҗә
66% - 90% - “уртача” дәрәҗә
50% - 65% - -“уртачадан түбән ”дәрәҗә
50% тан түбән - “түбән” дәрәҗә

**Обществознание и естествознание(Окружающий мир)(диагностическая работа)**

96% - 100% - уровень « высокий »

91% - 95 % - уровень «выше среднего».
66% - 90% - уровень «средний»,
50% - 65% - уровень «ниже среднего»,
Менее 50% - уровень «недостаточный»,

**Музыка**

**“Высокий” –**знание мелодической линии и текста песни, чистое интонирование и ритмически точное исполнение, выразительное исполнение.
**“Высше среднего”** –знание мелодической линии и текста песни, в основном чистое интонирование, ритмически правильное, пение недостаточно выразительное.
**“Средний”** –допускаются отдельные неточности в исполнении мелодии и текста песни, неуверенное и не вполне, иногда фальшивое исполнение, есть ритмические неточности, пение невыразительное.
**“Низкий”** –исполнение неуверенное, фальшивое.

**Изобразительное искусство**

“5 баллов” – работа выполнена в заданное время, самостоятельно, качественно и творчески.
“4 баллов” - работа выполнена в заданное время, самостоятельно, при выполнении композиции допущены небольшие ошибки, общий вид работы –аккуратный.
“3 балла” –работа выполнена в заданное время, самостоятельно, отдельные детали выполнены с ошибками, работа оформлена небрежно или не закончено в срок.
“2 балла” –ученик самостоятельно не справился с работой, при ее выполнении допущены большие ошибки, оформлена небрежно и имеет незавершенный вид.
5-3 балла –учебный материал 1 класса ученик освоил.
Меньше 3 баллов –не освоил.

**5.Сроки выставления отметок в журнал.**

Отметка за устный ответ выставляется учителем в дневник и классный журнал в день ее получения. Максимальное время проверки письменной работы - неделя после ее проведения, в старших классах при проведении сочинения – две недели. Отметки по итогам проверки письменных работ выставляются в классный журнал не позднее, чем на седьмой день после ее проведения.

**6. Выставление четвертных, полугодовых и годовых отметок**

6.1. За 2 – 3 недели до окончания четверти (полугодия) учитель – предметник информирует классного руководителя о предварительных отметках.

6.2. Все четвертные, годовые отметки должны быть выставлены не позднее последнего дня занятий в четверти (полугодии), году.

6.3. При выставлении четвертных, полугодовых и годовых отметок учитывается средний балл; берутся во внимание результаты контрольных работ, а также последние отметки, полученные на итоговых уроках.

6.4. При выставлении четвертной (полугодовой) отметки учитель руководствуется следующим:
- отметка «5» выставляется при наличии большего количества отличных отметок, при отсутствии неудовлетворительных отметок;
- отметка «4» выставляется при наличии большего количества отметок «4», при отсутствии неудовлетворительных отметок (однако, неудовлетворительная отметка не учитывается, если учащийся в течение четверти (полугодия) показал более высокие знания по этому же материалу и получил удовлетворительную отметку);
- отметка «3» выставляется при наличии большего количества удовлетворительных оценок;
- неудовлетворительная отметка «2» выставляется, если учащийся не усвоил изучаемый материал и имеет в основном отметки «2»;
- обучающимся, находящимся на лечении в лечебном заведении, где были организованы учебные занятия, учитывают отметки, полученные в лечебном заведении.

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Чт, 15 фев 2024 18:24:38 МСК
Идентификатор документа 44846915-e1f3-4381-899e-f23bc6eab71c 

6.5. При выставлении годовых отметок по предмету учитель руководствуется:
годовая отметка по предмету в 2-9 классах определяется на основании четвертных отметок.

**7. Права и обязанности обучающихся при получении отметки**

7.1. Обучающийся имеет право на публичное или индивидуальное обоснование отметки.

7.2. В случае неудовлетворённости обучающихся или их родителей выставленной отметкой они имеют право заявить об этом письменно администрации школы в срок не позднее 3 дней с момента сообщения об оценке.

7.3. Обучающемуся, вышедшему после длительного пропуска (более 3 уроков) на тематический контроль, неудовлетворительные отметки не выставляются в журнал.

ОТПРАВИТЕЛЬ
МБОУ "Средняя Общеобразовательная Школа №127" Приволжского Района Г.Казани

ПОДПИСАНО

ВЛАДЕЛЕЦ СЕРТИФИКАТА
ФЕРАФОНТОВА ФАРИДА АЛЬФАТОВНА

ДОЛЖНОСТЬ
Директор

СЕРТИФИКАТ
00C09958C723B2952D91351390544645F4

ПОДПИСАН
15.02.2024 18:24:31 МСК

ПОДПИСЬ ВЕРНА

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Чт, 15 фев 2024 18:24:38 МСК
Идентификатор документа 44846915-e1f3-4381-899e-f23bc6eab71c